**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

# К А Р А Р

19.11.2018 № 215

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 2496 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-1884, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 75,48% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1518 (80,57%) кеше тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 364 кеше тавыш бирде, бу 19,32% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге территориясендә **2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум** узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныргa.

2. "2019 елда, Үрнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш) үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-**Үрнәк** авылында: Наратлы урамы – 1-5а йорт, Тау асты ур., 5-10 йорт, Күпер ур.,11 йорт, Урман ур., 11 йорт; **Түбән Пошалым** авылы Пионер ур.,1-9 йорт; **Югары Пошалым** авылы Мичурин ур., 8-18 йорт, Урал ур., 1-6 йорт; **Урта Пошалым** авылы Сәйдәшев ур., 1-10 йорт; **Көтек** авылы Комсомол ур., 20-23 йорт, Мәктәп ур., 60-66 йорт; **Казанбаш** авылы Җиңү ур., 27-33 йорт, Киров ур., 1-36 йорт, Мәктәп ур., 96-105 йорт, Яшьләр ур., 126-134 йорт; **Дүртөйле** авылы Күпер ур., 1-5 йорт; **Апайкина** Гарь авылы Үзәк ур., 20-32 йорт; **Казанка** авылы Җиңү ур., 10-15 йорт; **Күлтәс** авылы Р. Мөбәрәкшин ур., 25-30 йорт, Г. Кәбиров ур., 10-15 йорт, Бертуган Зыятдиновлар ур., 21-25 йорт; **Гарталовка** авылы Урман ур., 20-25 йорт; **Иске Төрнәле** авылы Комсомол ур., 58-61 йорт;

- Кышкы чорда авылларда җирле үзәккә караган юлларны кардан чистарту.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

Үрнәк, Алга – Көек, Казанка авылларында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычларны, лампалар, үз-үзен изоляцияләгән үткәргечләрне, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, бушаткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

Алга -Көек, Апайкина Гарь, Кече Төрнәле авыллары янында рөхсәтсез чүплекләр урнаштырылган урыннардагы җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

Кече Төрнәле, Көтек, Үрнәк (ике чишмә), Казанбаш, Алга -Көек, Тылангыр авылларында чишмә территориясенә материаллар сатып алу, ремонтлау һәм төзекләндерү.

3. Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм күмү урыннарын булдыру:

- Югары Пошалым, Бимәр, Үрнәк, Тылангыр авылларында зират коймасын сатып алу һәм ремонтлау;
- Күлтәс авылында зиратны чиста һәм тәртиптә тоту өчен чүп-чар җыю контейнеры, бензокос, чылбыр сатып алу;
- Күлтәс, Иске Төрнәле авылларында зират эчендәге агачларны кисү;

4. Торак пунктлар янында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- түбәндәге торак пунктлар өчен мотопомп һәм аларга җиң сатып алу: Урта Пошалым авылы, Түбән Пошалым авылы, Казанбаш авылы, Кече Төрнәле авылы, Иске Төрнәле авылы, Алга -Көек авылы, Казанка авылы, Күлтәс авылы, Тылангыр авылы (һәр авылга бер штук);
- Үрнәк авылына янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Үрнәк авыл җирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

5. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Председатель территориальной
избирательной комиссии
Арского района
Республики Татарстан Б.И. Кадыров

Секретарь территориальной
избирательной комиссии
Арского района
Республики Татарстан Л.И. Нурмиева